ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» июнь 2020 ел № 187

Гражданнарны аз керемлеләр дип таныганда 2020 елга Әгерҗе муниципаль районында граждан керeменең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакын билгеләү методикасын раслау турында» 2018 елның 17 декабрендәге 816/пр номерлы, 2020 елның 13 мартындагы «2020 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 122/пр номерлы боерыклар нигезендә, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымта итеп бирелә торган гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен иң чик мәгънәләр итеп билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы чиге:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 749 792 сум;

1.1.2. ике кешелек гаилә өчен – 2 227 008 сум;

1.1.3. өч кешелек гаилә өчен – 2 863 296 сум;

1.1.4. дүрт кешелек гаилә өчен – 3 817 728 сум;

1.1.5. биш кешелек гаилә өчен – 4 772 160 сум;

1.1.6. алты кешелек гаилә өчен – 5 726 592 сум;

1.1.7. җиде кешелек гаилә өчен – 6 681 024 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 23 330,56 сум;

1.2.2. ике кешелек гаилә өчен – 14 846,72 сум;

1.2.3. ике һәм аннан күбрәк кешелек гаилә өчен – 12 725,76 сум.

2. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә гражданнарны аз керемле дип таныганда һәм торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрен кулланырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Шәмсетдиновка йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **А.Р. Вәлиев**